**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

01 нче декабрь 2020 ел Күзкәй авылы № 9

Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл
җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 еллар
план чорына бюджет проекты буенча
җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге халкының «2021 елга, 2022-2023 еллар план чорына Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге бюджеты проекты турында» гы карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 06.10.2003 ел № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законга, Күзкәй авыл җирлеге Уставына, "Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында" Нигезләмәсенә таянып,

**Карар:**

1. 2020 елның 01 декабрендә Күзкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советының «Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына бюджеты турында» гы карары проекты буенча тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны 2020 елның 01 декабреннән дә соңга калмыйча җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Билгеләргә:

3.1 халык тыңлаулары үткәрү вакыты – 11.12.2020 ел 14.00 сәгатьтә;

3.2 үткәрү вакыты – 1 көн;

3.3 үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Тукай районы, Күзкәй авылы, Ахметшина урамы, 20 йорт (Күзкәй авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы)

3.4 фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә ала торган адрес: ТР, Тукай районы, Күзкәй авылы, Ахметшина урамы, 20 йорт (эш көннәрендә-8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр)

4. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге башкарма комитетына «2021елга, 2022-2023 еллар план чорына Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге бюджеты турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Күзкәй авыл җирлеге башлыгы Э.Р. Гәрәев